# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында” 2008 елның 2 августындагы 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 8 (I өлеш); 2009, № 6; 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 3 пунктына “Россия Федерациясе оборонасын һәм иминлеген тәэмин итү максатларында федераль ихтыяҗлар өчен” сүзләрен өстәргә;

2) 2 статьяда:

а) “Нигезләмә” сүзен “1. Нигезләмә” сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

“2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пункты нигезләмәсе 2014 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалта.”.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. “Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында” 2008 елның 2 августындагы 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 3 пункты

нигезләмәләренең (әлеге Закон редакциясендә) гамәлдә булуы 2013 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 8 октябре
№ 72-ТРЗ